**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 8** **11.11.2025**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Урсай авыл җирлеге составына керүче
Мөслим авылында 2026 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Мөслим авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, бер тапкыр бирелә торган түләүне киметергә 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертергә һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материаллар, җайланмалар сатып алу, авария хәлләрен бетерү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (юлларны кардан чистарту).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:
-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Урсай авылы, Үзәк урамы, 60 йорт.
-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Мөслим авылы, Гафури урамы, 31 йорт

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үрсай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә

Рәис ____________ З.Х. Рахимьянова

УРСАЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1602002416
КПП 164301001